Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № №XIX-4**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 29 мае

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 24.02.2012 ел, №XV-2 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы мәнфәгатьләрендә гавами сервитутларны билгеләү һәм туктату тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 маддәсе, Татарстан Республикасы Җир кодексының 5 маддәсе, ”Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә гавами сервитутларны билгеләү һәм туктату тәртибе турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 12.08.2011ел, №660 карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 24.02.2012 ел, №XV-2 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы мәнфәгатьләрендә гавами сервитутларны билгеләү һәм туктату тәртибенә (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 12.07.2012 ел, № XVIII-8 карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 3 пунктта:

а) 1 пунктчаны “,шул исәптән гомуми файдаланудагы су объектына һәм аның яр буйларына гражданнарның ирекле керүен тәэмин итү максатларында да” сүзләре белән тулыландырырга;

б) 3 пунктчада “һәм геодезик билгеләр” т сүзләрен “дәүләт геодезия челтәрләре, гравиметрия пунктлары, нивелир пунктлары билгеләре, геодезик пунктлары” сүзләренә алмаштырырга;

в) 8 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “8) җир кишәрлеген ау, балыкчылык, аквакультура (балык җитештерү)максатларында файдалану;”;

г) 10 нчы пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

1.2) 14 пунктта “Күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алу турында” Федераль закон белән” сүзләрен “Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында” Федераль закон” сүзләренә алмаштырырга;

1.3) 15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“15. Гавами сервитутны билгеләү җир кишәрлеген куллануда шактый кыенлыкларга китерсә, аның милекчесе җирле үзидарә органыннан аның чамасына туры килә торган түләү таләп итәргә хокуклы.”;

1.4) 17 пунктта:

а) икенче абзацтагы “Палата тарафыннан туктатыла” сүзләрен “ Палата карары белән туктатыла” сүзләренә алмаштырырга;

б) өченче абзацта “Күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне Бердәм дәүләт реестрында” сүзләрен “Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрында” сүзләренә алмаштырырга;

1.5) 18 пунктның беренче абзацындагы “Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегендә” сүзләрен “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлектә” сүзләренә алмаштырырга;

1.6) 22 пунктның икенче абзацын түбәндәге эчтәлектәге җөмлә белән тулыландырырга:

“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе җәмәгать тыңлаулары беркетмәләрен саклау өчен җаваплы.”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев